**РАСПОРЯЖЕНИЕ**
РАИСА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
РӘИСЕ
**БОЕРЫГЫ**

14.03.2025 № 129

**Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасында Россия Федерациясе үсешенең илкүләм максатларына ирешү буенча чаралар координаторлары һәм Татарстан Республикасында Россия Федерациясе субъектлары югары вазыйфаи затлары эшчәнлеге һәм Россия Федерациясе субъектлары башкарма органнары эшчәнлеге нәтиҗәлелеген бәяләү күрсәткечләренең үтәлеше өчен җаваплы республика башкарма хакимият органнары исемлеген раслау турында» боерыгына үзгәрешләр кертү хакында**

Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасында Россия Федерациясе үсешенең илкүләм максатларына ирешү буенча чаралар координаторлары һәм Татарстан Республикасында Россия Федерациясе субъектлары югары вазыйфаи затлары эшчәнлеге һәм Россия Федерациясе субъектлары башкарма органнары эшчәнлеге нәтиҗәлелеген бәяләү күрсәткечләренең үтәлеше өчен җаваплы республика башкарма хакимият органнары исемлеген раслау турында» 2021 елның 19 мартындагы 116 номерлы боерыгына (Татарстан Республикасы Президентының 2021 елның 2 июнендәге 176 номерлы боерыгы һәм Татарстан Республикасы Рәисенең 2023 елның 11 маендагы 164 номерлы боерыгы нигезендә кертелгән үзгәреше белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

атаманы түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасында Россия Федерациясе субъектлары югары вазыйфаи затлары эшчәнлеге һәм Россия Федерациясе субъектлары башкарма органнары эшчәнлеге нәтиҗәлелеген бәяләү күрсәткечләренең үтәлеше өчен җаваплы координаторлар һәм республика башкарма хакимияте органнары исемлеген раслау турында»;

преамбуланы түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасында Россия Федерациясе Президентының «2030 елга кадәрге чорда һәм 2036 елга кадәр перспективада Россия Федерациясе үсешенең илкүләм максатлары турында» 2024 елның 7 маендагы 309 номерлы һәм «Россия Федерациясе субъектлары югары вазыйфаи затлары эшчәнлеге һәм Россия Федерациясе субъектлары башкарма органнары эшчәнлеге нәтиҗәлелеген бәяләү турында» 2024 елның 28 ноябрендәге 1014 номерлы указларын гамәлгә ашыру максатларында:»;

1 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1. Кушымтада бирелә торган Татарстан Республикасында Россия

Федерациясе субъектлары югары вазыйфаи затлары эшчәнлеге һәм Россия Федерациясе субъектлары башкарма органнары эшчәнлеге нәтиҗәлелеген бәяләү күрсәткечләренең үтәлеше өчен җаваплы координаторлар һәм республика башкарма хакимият органнары исемлеген (алга таба – Исемлек) расларга.»;

2 пунктның «д» пунктчасындагы «Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары, Татарстан Республикасының аерым дәүләт учреждениеләре эшчәнлеге нәтиҗәлелеген һәм халыкның тормыш сыйфатын бәяләү индикаторлары» сүзләрен «Республика башкарма хакимияте органнарына, Татарстан Республикасының аерым дәүләт учреждениеләренә идарә итүгә бирем» сүзләренә алмаштырырга;

4 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4. Федераль күрсәткечләрнең үтәлеше өчен җаваплы булган республика башкарма хакимият органнарының әлеге боерыкның 2 пунктын гамәлгә ашыру буенча эшчәнлеген гомуми координацияләүне Исемлектә күрсәтелгән координаторларга йөкләргә.»;

Татарстан Республикасында Россия Федерациясе үсешенең илкүләм максатларына ирешү буенча чаралар координаторлары һәм Татарстан Республикасында Россия Федерациясе субъектлары югары вазыйфаи затлары эшчәнлеге һәм Россия Федерациясе субъектлары башкарма органнары эшчәнлеге нәтиҗәлелеген бәяләү өчен күрсәткечләрнең үтәлеше өчен җаваплы республика башкарма хакимият органнары исемлеген түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

**«Татарстан Республикасында Россия Федерациясе субъектлары югары вазыйфаи затлары эшчәнлеге һәм Россия Федерациясе субъектлары башкарма органнары эшчәнлеге нәтиҗәлелеген бәяләү күрсәткечләренең үтәлеше өчен җаваплы координаторлар һәм республика башкарма хакимият органнары исемлеге**

| Т/с | Россия Федерациясе субъектларының югары вазыйфаи затлары һәм Россия Федерациясе субъектлары башкарма органнары эшчәнлегенең нәтиҗәлелеген бәяләү күрсәткеченең атамасы | Татарстан Республикасында Россия Федерациясе субъектларының югары вазыйфаи затлары эшчән-легенең һәм Россия Федерациясе субъектлары башкарма органнары эшчәнлегенең нәтиҗәлелеген бәяләү күрсәткечен үтәү өчен җаваплы республика башкарма хакимият органы | Татарстан Республикасында Россия Федерациясе субъектларының югары вазыйфаи затлары эшчәнлегенең һәм Россия Федерациясе субъектлары башкарма органнары эшчәнлегенең нәтиҗәлелеген бәяләү күрсәткечен үтәү өчен җаваплы координатор |
|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 |
| 1 | Хакимияткә ышаныч (Россия Федерациясе Президентына, Россия Федерациясе субъект-ларының югары вазыйфаи | республика башкарма хакимияте органнары | Сәфәров Әсгать Әхмәт улы – Татарстан Республикасы Рәисе Администрациясе Җитәкчес |

| 1 | 2 | 3 | 4 |
|---|---|---|---|
| | затларына ышаныч, аның дәрәҗәсе шул исәптән Россия Федерациясе субъектларында Россия Федерациясе үсешенең илкүләм максатларына ирешүгә карата җәмәгатьчелек фикерен бәяләү юлы белән билгеләнә) | | |
| 2 | Россия Федерациясе субъектының халкы саны | Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы; Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы | Фазлыева Ләйлә Ринат кызы – Татарстан Республикасы Премьер-министры урынбасары |
| 3 | Бала тудыруның гомумиләштерелгән коэффициенты | Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы (компетенциясе кысаларында); Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы (компетенциясе кысаларында); Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы (компетенциясе кысаларында) | Фазлыева Ләйлә Ринат кызы – Татарстан Республикасы Премьер-министры урынбасары |
| 4 | Бала туганда фаразланган гомер озынлыгы | Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы | Фазлыева Ләйлә Ринат кызы – Татарстан Республикасы Премьер-министры урынбасары |
| 5 | Фәкыйрьлек дәрәҗәсе | Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы; Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгы | Нигъмәтуллин Рөстәм Камил улы – Татарстан Республикасы Премьер-министрының беренче урынбасары |
| 6 | Гражданнарның физик культура һәм спорт белән шөгыльләнү шартларыннан канәгатьлеге | Татарстан Республикасы Спорт министрлыгы | Фазлыева Ләйлә Ринат кызы – Татарстан Республикасы Премьер-министры урынбасары |

| 1 | 2 | 3 | 4 |
|---|---|---|---|
| 7 | Махсус хәрби операциядә катнашучыларның медицина тернәкләндерүе, яңадан белем алу һәм эшкә урнаштыру шартларыннан канәгатьлеге | Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы (компетенциясе кысаларында); Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы (компетенциясе кысаларында) | Фазлыева Ләйлә Ринат кызы – Татарстан Республикасы Премьер-министры урынбасары |
| 8 | Белем бирү дәрәҗәсе | Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы | Фазлыева Ләйлә Ринат кызы – Татарстан Республикасы Премьер-министры урынбасары |
| 9 | Балалар һәм яшьләрнең сәләтләрен һәм талантларын ачыклау, аларга ярдәм күрсәтү һәм аларны үстерү системасының нәтиҗәлелеге | Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы; Татарстан Республикасы Спорт министрлыгы; Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре министрлыгы; Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгы | Фазлыева Ләйлә Ринат кызы – Татарстан Республикасы Премьер-министры урынбасары |
| 10 | Иреклеләр эшчәнлеге белән шөгыльләнүчеләр өлеше | Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре министрлыгы; Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы | Фазлыева Ләйлә Ринат кызы – Татарстан Республикасы Премьер-министры урынбасары |
| 11 | Гармонияле үсештәге, патриотик хискә ия булган һәм социаль җаваплы шәхес тәрбияләү өчен шартлар | Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгы; Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре министрлыгы; Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы; Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгы | Фазлыева Ләйлә Ринат кызы – Татарстан Республикасы Премьер-министры урынбасары; Шәйхразиев Васил Габделгаяз улы – Татарстан Республикасы Премьер-министры урынбасары |
| 12 | Торак шартларын яхшырткан гаиләләр саны | Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгы | Нигъмәтуллин Рөстәм Камил улы – Татарстан Республикасы Премьер-министрының беренче урынбасары |

| 1 | 2 | 3 | 4 |
|---|---|---|---|
| 13 | Торак һәм торак булмаган күчемсез милекне файдалануга тапшыру күләме | Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгы | Нигъмәтуллин Рөстәм Камил улы – Татарстан Республикасы Премьер-министрының беренче урынбасары |
| 14 | Төп торак пунктларда яшәү мохите сыйфаты | Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгы; Татарстан Республикасы Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгы; Татарстан Республикасы Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгы; Татарстан Республикасы Дәүләт идарәсен цифрлы нигездә үстерү, мәгълүмат технологияләре һәм элемтә министрлыгы; Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы; Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы; Татарстан Республикасы Спорт министрлыгы; Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгы; Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгы | Нигъмәтуллин Рөстәм Камил улы – Татарстан Республикасы Премьер-министрының беренче урынбасары; Фазлыева Ләйлә Ринат кызы – Татарстан Республикасы Премьер-министры урынбасары |
| 15 | Эре шәһәр агломерацияләре автомобиль юллары һәм төбәк әһәмиятенә ия автомобиль юлларының (автомобиль юлларының төп челтәренә караган юлларны да кертеп) нормативларга туры килә торган өлеше | Татарстан Республикасы Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгы | Нигъмәтуллин Рөстәм Камил улы – Татарстан Республикасы Премьер-министрының беренче урынбасары |
| 16 | Агломерацияләрдә һәм шәһәрләрдә эксплуатацияләү вакыты нормативтан артып китмәгән җәмәгать транспорты паркы өлеше | Татарстан Республикасы Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгы | Нигъмәтуллин Рөстәм Камил улы – Татарстан Республикасы Премьер-министрының беренче урынбасары |

| 1 | 2 | 3 | 4 |
|---|---|---|---|
| 17 | Әйләнә-тирә мохитнең сыйфаты | Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгы; Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгы; Татарстан Республикасы Урман хуҗалыгы министрлыгы | Нигъмәтуллин Рөстәм Камил улы – Татарстан Республикасы Премьер-министрының беренче урынбасары |
| 18 | Уртача айлык реаль хезмәт хакының үсеш темпы (үсеш индексы) | Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгы; Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы; Татарстан Республикасы Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгы; Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгы; Татарстан Республикасы Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгы; Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгы; Татарстан Республикасы Дәүләт идарәсен цифрлы нигездә үстерү, мәгълүмат технологияләре һәм элемтә министрлыгы | Шаһиәхмәтов Мидхәт Рәфкать улы – Татарстан Республикасы Премьер-министры урынбасары – Татарстан Республикасы икътисад министры; Коробченко Олег Владимирович – Татарстан Республикасы Премьер-министры урынбасары – Татарстан Республикасы сәнәгать һәм сәүдә министры; Җәббаров Марат Азат улы – Татарстан Республикасы Премьер-министры урынбасары – Татарстан Республикасы авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министры |
| 19 | Инфраструктур монополияләр (федераль проектлар) инвестицияләреннән һәм федераль бюджетның бюджет ассигнованиеләреннән тыш төп капиталга инвестицияләрнең физик күләме үсеш темпы (үсеш индексы) | Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгы; Татарстан Республикасының инвестицион үсеш агентлыгы; Татарстан Республикасы Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгы; Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгы; Татарстан Республикасы Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгы; Татарстан Республикасы | Шаһиәхмәтов Мидхәт Рәфкать улы – Татарстан Республикасы Премьер-министры урынбасары – Татарстан Республикасы икътисад министры; Коробченко Олег Владимирович – Татарстан Республикасы Премьер-министры урынбасары – Татарстан Республикасы сәнәгать һәм сәүдә министры; Җәббаров Марат Азат улы – Татарстан Республикасы Премьер- |

| 1 | 2 | 3 | 4 |
|---|---|---|---|
| | | Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгы;<br>Татарстан Республикасы Дәүләт идарәсен цифрлы нигездә үстерү, мәгълүмат технологияләре һәм элемтә министрлыгы;<br>Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы;<br>Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы;<br>Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы;<br>Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгы;<br>Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгы;<br>Татарстан Республикасы Спорт министрлыгы;<br>Татарстан Республикасының Туристлык буенча дәүләт комитеты | министры урынбасары – Татарстан Республикасы авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министры |
| 20 | Кече һәм урта эшкуарлык субъектының бер хезмәткәренә исәпләгәндә керемнәр үсеше темпы | Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгы | Шаһиәхмәтов Мидхәт Рәфкать улы – Татарстан Республикасы Премьер-министры урынбасары – Татарстан Республикасы икътисад министры |
| 21 | Дәүләт һәм муниципаль идарә, икътисадның төп тармакларының һәм социаль өлкәнең, шул исәптән сәламәтлек саклау һәм мәгариф өлкәләренең, «цифрлы камиллек»кә ирешүе | Татарстан Республикасы Дәүләт идарәсен цифрлы нигездә үстерү, мәгълүмат технологияләре һәм элемтә министрлыгы;<br>Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгы;<br>Татарстан Республикасы Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгы;<br>Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы;<br>Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау | Гафаров Шамил Хәмит улы – Татарстан Республикасы Премьер-министры урынбасары – Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппараты Җитәкчесе;<br>Шәйхетдинов Роман Александрович – Татарстан Республикасы Премьер-министры урынбасары |

| 1 | 2 | 3 | 4 |
|---|---|---|---|
| | | министрлыгы;<br>Татарстан Республикасы Спорт министрлыгы;<br>Татарстан Республикасының Туристлык буенча дәүләт комитеты | |

».

**Татарстан Республикасы Рәисе** **Р.Н. Миңнеханов**